**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**РАИФА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ**
**КАРАР**

2023 елнын 28 август №135

Раиф авыл җирлеге Советының 29.07.2021 №45 карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Раиф авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында (Раиф авыл җирлеге Советының 05.10.2022 № 89 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 27.12.2018 № 498-ФЗ Федераль законнар, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Раиф авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Раиф авыл җирлеге Советы:

1. Раиф авыл җирлеге Советының 29.07.2021 №45 карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Раиф авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә (Раиф авыл җирлеге Советының 05.10.2022 № 89 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба – кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. Кагыйдәләрне түбәндәге эчтәлектәге 1 нче кушымта белән тулыландырырга:

«1 нче кушымта
Раифа авыл җирлеге Советының 29.07.2021 №89 карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Раифа авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре

**Исемлек**

**Зеленодольск муниципаль районы Раифа авыл җирлеге**

**территориясендә хайваннарны хуҗасыз кайтару тыела торган урыннар"**

1. Балалар уен һәм спорт мәйданчыклары, актив спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар.

2. Җәмәгать территорияләре (парклар, скверлар территорияләре, күпләп ял итү урыннары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буйлары).

3. Мәгариф оешмалары һәм сәламәтлек саклау оешмалары территорияләре, күрсәтелгән оешмаларга якын территорияләр.

4. Мәдәният һәм сәнгать объектларына якын территорияләр.

5. Җәмәгать туклануы оешмаларына, сәүдә объектларына, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннарына якын территорияләр.

6. Зират.».

2. Хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына хуҗасыз кайтару турында Карар кабул итүгә вәкаләтле затларның түбәндәге исемлеген билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Раиф авыл җирлеге башлыгы;

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Раиф авыл башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Раифа авыл җирлегенең Бело-Безводное авылы, Юбилейная урамы, 13 йорт (Раифа Башкарма комитеты) адреслары буенча урнашкан мәгълүмати стендларында; Раифа ав., Центральная урам, 7 йорт.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә.

Раиф авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе — И. Г. Нуриев